Нигъмәтуллина, З. Ак калфаклы рәссам / З. Нигъмәтуллина // Сөембикә. – 2024. – №1. – Б. 64-65.









# АК КАЛФАКЛЫ РӘССАМ

Чаллының талантлы рәссамы, Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Тәслия Мәҗитова 1957 елның 21 июлендә Мөслим районының Сөякәй авылында туган. «Җаным-тәнем белән җиргә берегүем сәбәпле, авылыбызның бар яме, табигате кадерен беләм, туган авылым күренешләрен киндерләремдә еш сурәтлим», – ди рәссам ханым.

Тәслия Мәҗитова 1979 елны Лениногорск педагогика училищесының сынлы сәнгать-графика бүлеген тәмамлаган. Мөслимнең Әмәкәй урта мәктәбендә балалар укыткан. 1984 елдан «КАМАЗ»ның Автомобильләр җыю заводына рәссам-бизәүче булып эшли башлаган. Ире Гамил белән балалары Альберт һәм Ләйсәнне үстергән. «Улыбыз – төзүче, кызыбыз – рәссам-проектлаучы. Кул эшләнмәләре остасы Ләйсән сәйлән белән төрле картиналар да чигә», – ди Тәслия ханым.

Оста үзенең үзенчәлекле картиналарын 40 яшендә генә иҗат итә башлаган. Алар – экспрессив, реалистик сынлы сәнгать мәктәбе кануннарына нигезләнгән импрессионизм юнәлешендәге әсәрләр. Чаллы дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетында читтән торып укый башлавы да нәкъ шул елларда. Әүвәл пейзажлар иҗат иткән, аннары натюрморт жанрын ошата төшкән. «Мондый ясау рәвеше үзеннән-үзе барлыкка килде кебек... Тормышны бик яратуым, аны һәрвакыт куанып кабул итүем бар хезмәтләремдә дә чагыла», – ди ул. Киндерләрендәге динамика, энергетика куәте, төс палитрасы, кабатланмас язу стиле белән башкалардан аерылып торган чын талант ул Тәслия Мәҗитова.

Беренче шәхси күргәзмәсен рәссам ханым 2005 елда Чаллы картиналар галереясында ачкан. Шәхси күргәзмәләре районнарыбызда, шәһәрләребездә еш оештырылган. Этнография белән бәйле картиналарының күбесе шәхси тупланмаларда, музейларда, картина галереяларында урын алган.

«Өебездә әнкәйнең чигүле мендәр тышлары, тәрәзә пәрдәләре, челтәрле тастымаллары һәм башка кул эшләнмәләре җитәрлек иде, хәзер аларның барысы да үземдә саклана инде. Яңа композицияләр төзегәндә аларны еш кулланам. Әнием Әсхия рәсем ясавымны бик тә ошата, бар уңышларыма сөенә иде!» – дип искә ала ул.

Тәслия ханым Чаллыдагы 52 нче татар урта белем бирү мәктәбендә рәсем дәресләре алып бара. 2023 елда Россиянең рәсем укытучылары арасында уздырылган дәрәҗәле конкурста катнашып, «Сынлы сәнгать» номинациясендә беренче урынны яулавы үзе үк рәссамның таланты хакында сөйли.


Тәслия ханым матур идеяләр белән яши. Рәссам Рауза Иванова-Латыйпова белән бергә «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасының Чаллы бүлеге әгъзаларын туплап, республика һәм халыкара күләмдәге «Ак калфаклы рәссамнар» оешмасын төзергә, киләчәктә Татарстан, Россия хатын-кыз рәссамнарының һәм гамәли сәнгать осталарының иҗат эшләрен башка дәүләтләрдә дә экспозицияләргә тели ул. Безгә дә «Ак калфаклы рәссамнар» оешмасының күргәзмәләрен күрергә насыйп булсын.


Тәслия Мәҗитова әнә шундый ак уйлы, ак хыяллы, ак калфаклы рәссамыбыз ул безнең.


Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА




Scanned with AnyScanner









ТӘСЛИЯ МӘҖИТОВА

Scanned with AnyScanner